ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2022 г. Заинск № 250

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Полиция хезмәткәрләренең балаларына социаль ярдәм күрсәтү максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Төп максатлар һәм бурычлар 2 бүлегенең 2.1.6 пунктына «яңа гына хезмәткә кабул ителгән полиция хезмәткәрләре балалары» сүзләрен өстәргә;
1.2. Түләүсез тукландыру тәртибе 5 нче бүлегенең 5.2 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:
“- балигъ булмаган ике һәм аннан да күбрәк баласы булган, йә бердәнбер ата-ана (законлы вәкилләр) булып торучы яңа эшкә урнашкан полиция хезмәткәрләренең балалары, беренче хезмәт елында»;
1.3. Түләүсез тукландыру тәртибе 5 нче бүлегенең 5.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11 абзац белән тулыландырырга: “- балигъ булмаган ике һәм аннан да күбрәк баласы булган, йә бердәнбер ата-ана (законлы вәкилләр) булып торучы яңа эшкә урнашкан полиция хезмәткәрләренең балалары, беренче хезмәт елында:
- ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) язмача гариза;
- туу турында таныклык;
- полиция хезмәткәре булган ата-ананың эш урыныннан белешмә».

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42